КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 июль г.Казань № 643

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 15 октябрь, 562 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 15 октябрь, 562 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 28 апрель, 258 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Азсыешлы суднолардан файдаланып, сулыкларда ярышлар (регаталар), су бәйрәмнәре, экскурсияләр һәм башка массакүләм чаралар үткәрү, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган

зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (алга таба – баш идарә), Федераль балыкчылык агентлыгының Урта Идел территориаль идарәсенә караган Татарстан Республикасы буенча су биологик ресурсларына дәүләт контроле, күзәтчелеге һәм аларны саклау бүлеге, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән, ә суднолар йөри торган су объектларында – Су юлларының һәм судночылыкның Казан районы – «Эчке су юлларының Идел бассейны администрациясе» федераль бюджет учреждениесе филиалы, Су юлларының һәм судночылыкның Түбән Кама районы – «Эчке су юлларының Кама бассейны администрациясе» федераль бюджет учреждениесе филиалы белән килештереп, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә».

Югарыда күрсәтелгән чараларны үткәргәндә оешмалар җитәкчеләре суда кешеләрнең иминлеге, җәмәгать тәртибе һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгели.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Татарстан Республикасы территориясендә әлеге Кагыйдәләр таләпләренең үтәлешен тикшерүдә тотуны баш идарә, үз компетенцияләре чикләрендә контрольнең (күзәтчелекнең) тиешле төрләре кысаларында башка органнар гамәлгә ашыра.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Су объектларында аз үлчәмле судноны файдалану гражданнар тарафыннан бу Кагыйдәләр, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Эчке су юллары шлюзлары аша судноларны үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 3 мартындагы 58 номерлы боерыгы белән расланган Эчке су юллары шлюзлары аша судноларны үткәрү кагыйдәләре, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Эчке су юллары буенча суднолар йөзү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 19 гыйнварындагы 19 номерлы боерыгы белән расланган Эчке су юллары буенча суднолар йөзү кагыйдәләре, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Россия Федерациясе су объектларында азсыешлы судноларны файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 6 июлендәге 487 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе су объектларында азсыешлы судноларны файдалану кагыйдәләре, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Россия Федерациясендә азсыешлы судноларны куеп тору өчен базалардан (корылмалардан) файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 20 июлендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә азсыешлы судноларны куеп тору өчен базалардан (корылмалардан) файдалану кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән

расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.3 һәм 2.4 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Һәр азсыешлы судно бәрелешүне кисәтү өчен гамәлләр кылу мөмкинлеге һәм тиешле шартларда һәм хәлләрдә таләп ителә торган ераклыкта туктату мөмкинлеге булган куркынычсыз тизлек белән барырга тиеш.

Портлар, пристаньнар, азсыешлы судноларны куеп тору урыннары өчен базалар (корылмалар), пляжлар һәм су объектларында халыкның башка күпләп ял итү урыннары чикләрендә, су астындагы эшләр белән шөгыльләнүче суднолар янында хәрәкәт иткәндә, куркынычсыз тизлек башка судноларга, йөзә торган корылмаларга, гидротехник һәм причал корылмаларына зыян сала торган дулкыннар барлыкка килүне булдырмаска тиеш.»;

2.6 пунктта:

2.6.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы акваториясенә керергә һәм анда хәрәкәт итәргә.»;

2.6.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.3. Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре акваториясенә керергә, әгәр әлеге тыю мондый территорияләрнең махсус саклау режимнарында каралган булса.»;

2.6.6 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Азсыешлы судноларны куеп тору урыннары өчен база (корылма) (алга таба – куеп тору базасы) дигәндә азсыешлы судноларны куеп тору һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән инженерлык корылмалары комплексы аңлашыла.

Куеп тору базаларына яр буенда урнашкан һәм (яки) су объекты акваторияләрендә урнашкан түбәндәге су объектын кертеп карарга кирәк:

азсыешлы судноларны тарттырып бәйләп кую, китереп туктату, аларга йөкләр төяү (алардан бушату), кешеләр утырту (алардан төшерү), азсыешлы судноларны куеп тору һәм (яки) саклау өчен билгеләнгән махсус оештырылган яр буе һәм (яки) йөзмә корылмалар;

азсыешлы судноларны илтеп җиткерү, эксплуатацияләү, куеп тору, аларга хезмәт күрсәтү һәм (яки) аларны саклау өчен билгеләнгән, технологик үзара бер-берсе белән тоташкан биналар, корылмалар һәм җиһазлар комплекслары;

азсыешлы суднолары булган эзләү-коткару формированиеләре объектлары (су-коткару станцияләре).

Судно хуҗасы (аннан файдаланучы) – физик зат тарафыннан оештырылган, аның өй янындагы участок чикләрендә урнаштырылган, үзенеке булган индивидуаль азсыешлы судноны китереп туктату, аңа йөкләр төяү (аннан бушату), кешеләр утырту (аннан төшерү), аңа мөстәкыйль хезмәт күрсәтү, куеп тору һәм (яки) саклау өчен файдаланыла торган куеп тору урыны куеп тору базасы булып тормый.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Куеп тору базарларын оештыру һәм урнаштыру Россия Федерациясенең су, җир, шәһәр төзелеше законнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый һәм хокукый актлары таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

Азсыешлы судноларның хуҗалары (алардан файдаланучылар) бу Кагыйдәләрне, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Россия Федерациясендә азсыешлы судноларны куеп тору өчен базалардан (корылмалардан) файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 20 июлендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә азсыешлы судноларны куеп тору өчен базалардан (корылмалардан) файдалану кагыйдәләрен, милекчеләре яки милекчеләре тарафыннан суднолар йөзәргә чыкканда иминлекне тәэмин итү буенча куеп тору базаларының вазыйфаи затлары таләпләрен үтәргә вәкаләтле затлары тарафыннан билгеләнгән куеп тору базаларыннан файдалану режимнарын үтәргә тиеш.»;

3.3 – 3.8 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Кагыйдәләргә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин